| СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 25.10.2022 | с. Печищи | № 25-129 |

Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Уставы белән

Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге Советының
карар итте:

1. Печищи авыл җирлегенең 2018 елның 25 апрелендәге 33-159 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына (2020 елның 29 октябрендәге 2-15 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Караргa 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге Советының
2022 елның «25» октябреннән
№ 25-129 карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет секретаре | 15904 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

12 нче кушымта
Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге Советының
2022 елның «25» октябреннән
№ 25-129 карарына

Печищи авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан районының Печищеи авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рахматуллина